Татарстан Республикасы Азнакай районы газетасы

Чәршәмбе №85 (13664) 23 ноябрь 2022 ел

# МАЯК

Газета 1930 елның 15 мартыннан чыга 16+

Яңалыкларны www.aznakaevo-rt.ru сайтында һәм социаль челтәрләрдәге төркемнәребездә укыгыз

# Балаларның физик һәм рухи сәламәтлеге мөһим

Сәламәт тәндә – сәламәт акыл. Шуңа күрә балаларга белем һәм тәрбия бирү белән бергә аларның сәламәтлеген саклау да мөһим.

Мәгариф

Резеда **ШӘРИПОВА**

**Тикшерүләр күрсәткәнчә, соңгы вакытта укучыларның еш авыруы, беренче сыйныфка килгәндә үк 30 процентка якын баланың сәламәтлеге буенча нинди дә булса тайпылышы күзәтелә.**

Мәктәпләрдә гамәлгә ашырыла торган сәламәтлек саклау технологияләре нәкъ менә кече яшьтән үк балаларның физик активлыгын арттыру һәм психикасын ныгытуга юнәлдерелгән.

Азнакай 1 нче урта мәктәбе базасында узган төбәкара семинар да шушы темага багышланды. Анда Азнакай, Менделеевск, Башкортстанның Бакалы районнарыннан 170 педагог катнашты. Мондый семинар биредә дүртенче елын уздырыла.

Кунакларны район башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Дамир Гыйләҗев, Азнакай мәгариф идарәсе җитәкчесе Зөлфия Гыйләҗева сәламләде.

Алар билгеләп узганча, районыбызда спорт белән шөгыльләнү өчен мөмкинлекләр җитәрлек.

– Барлык мәктәпләрдә спорт секцияләре эшли. Былтыр 1 нче мәктәптә хоккей классы ачтык. Тәрбияне балалар бакчасыннан ук башларга уйлап, шәһәребезнең 1 нче балалар бакчасында хоккей төркеме ачарга планлаштырабыз. Өч мәктәп футбол буенча проектта катнаша. Районның ике мең ярым укучысы "Всеобуч" программасы буенча "Дельфин", "Көмеш су" спорт комплексларында һәм 1 нче мәктәптә йөзәргә өйрәнә, – дип Зөлфия Гыйләҗева кунакларны сәламәтлек саклау юнәлешендә мәгариф учреждениеләрендә башкарыла торган эшләр белән таныштырды.

Социаль-гуманитар белем бирү үзәге доценты, педагогия фәннәре кандидаты



Азнакай 1 нче мәктәбе укучылары спорт ярата./ ФОТО: РЕЗЕДА ШӘРИПОВА.

Альберт Ибәтуллин мәгарифкә булган җитди игътибар, җылы кабул итүләре өчен Азнакай районы хакимиятенә рәхмәтен белдерде.

– Бүген мәгариф безнең алга балаларның физик сәламәтлеген генә түгел, рухи һәм психик сәламәтлеген дә кайгыртуны бурыч итеп куя, – дип ассызыклады ул үзенең чыгышында.

Пленар өлештән соң педагоглар төрле фәннәр буенча ун секциягә бүленеп, эшчәнлекләрен дәвам иттеләр, сәламәтлек саклау технологияләре буенча тәҗрибә урталаштылар.

– Мин "Яшь җиңел атлет" программасы буенча эш алып барам. Җиңел атлетика – ул һәр спорт төренең нигезен тәшкил итә, – ди Актүбә 1 нче урта мәктәбе укытучысы Сергей Соколов.

Азнакай 8 нче урта мәктәбенең физкультура укытучысы Фәварис Ильясов укучыларны үз фәненнән олимпиадаларга әзерләү тәҗрибәсен бәян итте. Аның укучылары республика, төбәк олимпиадаларында призлы урыннар яулап киләләр.

Мәктәпләрдәге "Үсеш ноктасы" үзәкләре дә сәламәтлек саклау технологияләрен практик кулланырга мөмкинлек бирә.

– Тормыш иминлеге дәресләрендә балалар беренче ярдәм күрсәтергә, шахмат түгәрәкләрендә логик фикерләргә өйрәнәләр, – ди Тымытык мәктәбе директоры Фирүзә Кашапова.

– Безнең балалар футбол, волейбол түгәрәкләрендә яратып шөгыльләнәләр. Кул көрәше буенча ярышларда беренче урыннарны алып киләбез. Әле менә 4 укучыбыз республика ярышына әзерләнә, – ди Чалпы мәктәбе укытучысы Рүзәл Гыймаев.

Сәламәтлек саклау технологияләре физкультура дәресләре белән генә чикләнми. Семинарда гуманитар һәм табигый фәннәр буенча да педагоглар мастер-классларда тәҗрибә тупладылар.

Соңыннан семинарда катнашучыларга "Парус" спорт-туристик базасында "Спорт-сәламәтләндерү сукмагы", "Туристик ориентлашу" проектларының гамәлдәге тәҗрибәсе тәкъдим ителде.



## "Маяк"тан бүләк отарга ашыгыгыз!

*2023 елның беренче яртыеллыгына "Маяк" газетасына язылу дәвам итә.*

**Ярты елга язылу бәясе – 849,42 сум.**

Газетабызга, үзегез килеп алу шарты белән, редакциянең рекламалар бүлегендә 480 сумга язылырга мөмкин.

14-24 ноябрьдә әбүнәчеләр арасында без вертикаль тузан суырткыч уйнатачакбыз!

Газетага язылып, квитанцияләрегезне azmayak@mail.ru электрон почтасына юллагыз. Бүләк 25 ноябрьдә 15.00 сәгатьтә уйнатылачак.

***Акцияне оештыручы: «Маяк» газетасы редакциясе. Акция 2022 елның 18 октябреннән 30 декабренә кадәр үткәрелә.***

***Тулырак мәгълүмат: aznakaevo-rt.ru сайтында.*** 16+ Реклама

«Маяк»
Чәршәмбе №85 (13664) 23 ноябрь 2022 ел

Яңалыкларны aznakaevo-rt.ru сайтында һәм социаль челтәрдәге төркемнәребездә укыгыз

Яңалыклар



**БӨТЕНРОССИЯ СЪЕЗДЫНДА КАТНАШТЫЛАР**

Азнакай районы мәгариф идарәсе җитәкчесе урынбасары Нәфисә Шәфыйкова һәм методист Эльвира Сәитова Мәскәүдә узган мәктәпкәчә яшьтәге белем бирү хезмәткәрләренең VII Бөтенроссия съездында катнаштылар.

Нәфисә Шәфыйкова балалар бакчасы һәм әти-әниләр хезмәттәшлеге буенча районның эш тәҗрибәсе белән уртаклашты.



**ЮЛЛАРДА АШЫКМЫЙК**

Машинада ашыгып йөрүнең кайчан да булса фаҗига белән тәмамланасы билгеле булса да, куучылар гына кимеми. Бигрәк тә кышкы юлларның саклык соравын барыбыз да беләбез. Якшәмбе көнне Азнакай – Тымытык юлында өч машина катнашында юл һәлакәте булды.

Тикшерү барышында Азнакайдан Тымытык юнәлешендә хәрәкәт иткән “Лексус” машинасы шоферының хәвефсез аралыкны сакламавы ачыклана. Ул Сәпәй авылы кырында алдан барган “Тойота” автомобиленә килеп бәрелә. Соңгысы исә, бәрелүдән каршы як полосага чыгып, Азнакайга таба хәрәкәт иткән “Лада” машинасы белән бәрелешә. Һәлакәттә “Лада” автомобиленең өч пассажиры төрле тән җәрәхәтләре ала. Бәхеткә, барысы да иминлек каешын эләктергән, балалар да махсус креслода була. Бот сөяге сынган 2021 елгы бала Әлмәт шәһәре сырхауханәсенә озатыла.



**ИГЪТИБАРЛЫ БУЛЫГЫЗ: МАГНИТ ДАВЫЛЛАРЫ КӨТЕЛӘ!**

25, 26 һәм 30 ноябрь көннәрендә магнит давылы үзен сиздерергә мөмкин. Бу көннәрдә үзебезнең, шулай ук якыннарыбызның сәламәтлегенә игътибарлырак булыйк!

# Муниципаль хезмәткәрләр – футбол буенча республикада икенче!

Республика муниципаль хезмәткәрләре арасында спартакиада дәвам итә.

Спорт

**Узган атнада футбол командалары арасында көчләләр ачыкланды.**

Әлмәт шәһәрендә 17-18 ноябрьдә узган мини-футбол турнирында Азнакай, Казан, Зәй, Яшел Үзән, Яр Чаллы, Түбән Кама, Нурлат, Бөгелмә, Чистай, Лениногорск, Алабуга командалары катнашты. Киеренке көрәштә район башлыгы Марсель Шәйдуллин җитәкчелегендәге муниципаль хезмәткәрләр командасы Бөгелмә, Чистай, Яр Чаллы уенчыларын артта калдырып икенче урынга лаек булдылар. Беренче урында – Казан спортчылары.



Муниципаль хезмәткәрләр спартакиадасы кысаларында барлыгы ун спорт төре буенча ярышлар каралган. Алар нәтиҗәләре буенча республиканың иң көчле муниципаль хезмәткәрләре командасы ачыклана.

# Шахмат – акыл ярышы

Район турниры

**Соңгы елларда районыбызда шахмат хәрәкәтен үстерүгә игътибар артты: Балалар иҗаты үзәгендә шахмат түгәрәкләре алып барыла, шәһәребездә шахмат клубы эшли, мәктәпләрдә, балалар бакчаларында шахмат зоналары ачылды.**

Бу көннәрдә шахмат клубында ир-атлар һәм хатын-кызлар арасында ярышлар үтте. Ул коррупциягә каршы көрәш айлыгы кысаларында уздырылды.

Муниципаль район башлыгы урынбасары Роза Галеева уенчыларга уңышлар юллап, турнирга килгән командаларга рәхмәтен җиткерде.

Ярышларны ачу тантанасында шәһәр прокуроры ярдәмчесе Илмира Камалиева да катнашты. Үзенең чыгышында ул прокуратура тарафыннан алып барылган чаралар белән таныштырды.

Шахматчы Галина Матюшенко Урсай авылыннан ук килгән.

– Турнир турында киявем әйткәч, килергә булдым. Безнең өйдә шахматны барысы да уйный: балалар да, оныклар да. Фикер йөртергә өйрәнергә, башны “эшләтергә” бик әйбәт, – ди ул.



Урманай авылыннан килгән Елена Кәрамованы шахмат уйнарга малае Роберт өйрәткән.

**– Районыбызда шахмат белән кызыксынучылар саны тагын да артсын иде, – ди Елена.**

“Коррупция – шахматчылар күзлегеннән” дип аталган әлеге район турнирында хатын-кызлар арасында Нурия Нургалиева җиңү яулады (район башкарма комитеты). Гүзәл Тимбакова (район башкарма комитеты) – икенчедә, Галина Матюшенко – өченчедә.

Ир-атлар арасында Фәнүс Ахунҗанов (шәһәр башкарма комитеты) беренче булды. Мөдәрис Ханнанов (“Витязь”) – икенче, Зөфәр Муллин (ветераннар советы) өченче урынга лаек булды.

# Өлкәннәрдән үрнәк алыйк!


***Безнең район өлкәннәре һич тынгы белми: әле генә авыл хуҗалыгы предприятиеләрендә алар, әле генә мәдәни чараларда катнашалар, әле генә сәяхәттә үзләре... Ул гына да түгел, бүген инде өлкән яшьтә булуларына карамастан, спортта да сер бирмиләр алар: шахмат уйнау, чаңгы шуу, скандинав таяклары белән йөрү дисеңме?! Аларның дәрт-дәрманына яшьләр дә көнләшерлек!***

Спорт

Таңсылу **Саниева**

**Бүген ветераннар арасында иң шәп йөзүчеләрне ачыкладылар: шәһәр бассейнында йөзү буенча район турниры үтте. Ерак дип тормаганнар, авыллардан да килүчеләр күп иде.**

**– Спорт белән шөгыльләнү өчен менә дигән мөмкинлекләребез бар! Шуңа моннан файдаланырга кирәк. Киләчәктә дә бүгенге кебек актив булып яшәргә язсын, – ди район ветераннар советы рәисе Миргасим Кәримов.**



Өлкәннәребез 25 метр арага йөзүдә ярышты. Монда беренчелекне Кәкре Елга авыл җирлеге ветераннар советы рәисе Илмир Гарипов алды.

– Яшь чакта су буеннан кайтып керми идек. Бүген дә, бассейнга йөрмәсәм дә, бик иркен йөзәм. Без бит авыл малайлары! – ди ул.

Икенче урынны Рәфис Солтангиров яулады, Наил Гарифуллин өченче йөзеп килде.

Өлкән спортчыларны район физик культура һәм спорт идарәсе җитәкчесе Рәфис Миңнеханов та сәламләп, бүген дә сәламәт яшәү рәвеше алып барган ветераннарга рәхмәт әйтте.

Ярышлар йөзү белән генә тәмамланмады. Өлкәннәребез гер күтәрү, урындыктан иелү, йөзү буенча ГТО нормативларын да тапшырдылар. Дартста алдынгылар да ачыкланды.

Гер күтәрүдә Рәфәт Динеевка тиңнәр булмады. Фәнил Зиязов икенче урынны алды. Аннан әз генә калышып, Сәгадәт Кәримов өченче булды.

Урындыктан иелүдә Борис Овчаркин беренчелекне яулады. Фаяз Зәйдуллин – икенче, Зирәк Хәйруллин – өченчедә.

Бәйрәмгә әйләнгән спорт чарасы мул чәй табыны артында тәмамланды. Өлкәннәребезне район башкарма комитеты рәисе Айдар Шәмсетдинов та тәбрикләп, аларның һәрберсенә Мактау грамоталары һәм бүләкләр тапшырды.

**Әбүнә – 2023**

# “МАЯК” – Әниләр көненә иң шәп бүләк!

*Ноябрь ахырында Әниләр көнен билгеләп узабыз. Бу бәйрәм исегездән чыкмадымы? Әниләрегезгә нәрсә бүләк итәргә белмисезме? Бер дә аптырап тормагыз, районыбызның “Маяк” газетасына язылу бүләк итегез! Алар ярты ел буе сезгә рәхмәт әйтеп, рухи азык алырлар. “Маяк” газетасына мин язылдым. Сез дә язылыгыз!*



**Фаяз Зәйдуллин,
Түйкә авылы**

**ӘНИЛӘР КӨНЕ БЕЛӘН**

Әби белән бабай яши,
Әй лә, ялгыш,
Бабай белән әби яши –
Менә дөрес,
Бусы – язмыш.
Балалары – өчәү, дүртәү,
Әллә бишәү...
Оныклары да бер дистә,
Күпләр инде,
Әллә ничәү.
Тыныч кына шулай бергә
Яшәгәндә
Тавыш-тын чыгармый гына
Әкрен генә
Көн күргәндә,
Килеп җитә икән бит, әй,
Әни көне.
Бабай белми нишләргә дә,
Йөри чабып,
Белми тынгы.
Әни бит ул – барчабызга
Изге бер зат.
Әби дә шул исемлектә,
Ул да әни,
Ул бит – олпат.
Әни көне әни өчен,
Әби өчен,
Ир-атларга тынгы бирмәс,
Мәшәкатьле
Булсын бер көн.
Булып торсын әни белән
Әби көне,
Сез безнең өчен бик кирәк,
Картаймагыз,
Сез – кадерле.
Әби белән бабай шулай
Яшәсеннәр,
Оныкларга маяк булып
Үрнәк булып
Яшәрсеннәр.
Бүләгегез әниләргә
Гәҗит булсын,
Ул гәҗитнең исеме дә,
Җисеме дә
“Маяк” булсын.

# Син булганга, яшәү матур!

Яшь каләмчеләр иҗаты

Рәхмәт, әнием! Рәхмәт әйтеп сиңа башлыйм сүземне. Синең булганың өчен, безне кайгыртканың өчен рәхмәт, әнием! Син булганга өебез нурлы, җылы һәм якты. Без нинди бәхетле балалар, дип уйлап куям, чөнки безнең горурланырлык әниебез бар. Әни янәшәсендә әтиебез бар!

Кадерле әниемнең исеме – Гөлнара. Исеме дә “гөл” сүзеннән башлангангамы, ул бүлмә гөлләре, чәчәкләр үстерергә ярата. Бу шөгыленең серләрен безгә дә өйрәтә. Бервакыт мин олы абыем белән төрле төстәге глоксиния гөлләрен утыртырга булдык. Әниебез аларга нинди туфрак әзерләргә, ничегрәк утыртырга кирәклеген аңлатты. Ул гөлләр әле дә бүлмәләрне бизәп утыралар.

Бакчада эшләү дә аның яраткан шөгыле. Бакчадагы һәр үсемлекне үз баласыдай тәрбияләп үстерә ул.

Безнең гаиләбез зур. Әниебез биш балага гомер биргән, бүген инде ул өч оныкның яраткан әбисе дә. Без бергәләшеп табигать кочагына чыгабыз, өйдә бәйрәм табынына җыелабыз. Әнинең аш-суга осталыгы да шунда күренә. Үзенә ошаган ризыклар әзерләү рецептларын да җыеп бара ул. Әниебезнең туган көнендә милли ризыгыбыз – бәлеш пешердек. Аның эчлеген әзерләүдә мин дә булыштым. Тәмле, шулпалы бәлеш телеңне йотарлык иде.

Бөтенебезне кайгыртучы кояшка тиң әниебез булганда, яшәү матур да, күңелле дә!

**Самира Хөснуллина,
Азнакай шәһәре 9 нчы гомуми урта белем мәктәбенең 7 нче сыйныф укучысы**

# Сорау-җавап

**Салым органыннан бирелгән ИНН кәгазен югалткан очракта, аны каян алып була?
*Ләйсән Сабурова, Азнакай***

Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсеннән хәбәр итүләренчә, физик затны исәпкә кую турындагы электрон таныклыкны «Физик затлар өчен шәхси кабинет» сервисы аша бушлай алырга мөмкин. Электрон имза белән имзаланган әлеге документ салым органының вазифаи заты кул куйган һәм мөһер белән расланган кәгазь күчермәсе кебек үк юридик көчкә ия.

ИНН алу өчен сайтта «Жизненные ситуации» бүлегенә керергә һәм физик затны салым органында исәпкә кую турындагы гаризаны җибәрү дә җитә. «Профиль» бүлегендә аны үзегезгә кирәк вакытта таба алачаксыз.

Исем-фамилия, туган көн яки туган урынны үзгәртү очракларында физик затны исәпкә кую турында яңа таныклык биргән өчен дәүләт пошлинасы алынмый.

Реклама

**САТЫЛА**

1615 Тымытык авылында кирпеч йорт. Тел. 8-987-004-66-91.

**1528** Каз, мулард, суярдай бройлер. Тел. 8-917-936-12-84.

1560 Утын. Тел. 8-987-222-18-32.

1609 Утын. Каен. Имән. Тел. 8-904-713-98-15.

1616 Арпа. Печән. Тел. 8-908-33-49-659.

**САТЫП АЛАМ**

1370 Итләтә һәм тереләй мал. Тел. 8-917-435-41-04.

**ХЕЗМӘТЛӘР**

1545 Ремонт стиральных машин на дому. Тел. 8-919-695-65-91.

1544 Натяжные потолки. Тел. 8-917-851-81-96.

1530 Диваннар тышлыйбыз. Тел. 8-917-873-82-53.

1514 Скорая помощь Вашей стиральной машине. Гарантия. Тел. 8-927-424-19-18.

1569 Откачка канализации. Тел. 8-987-273-34-40, 8-987-220-63-88.

1580 Услуги сварщика, выезд. Тел. 8-917-918-8-917.

**ЭШ**


1583 Требуются водители категории «Д» с картой водителя. Заработная плата достойная. Тел. 8-927-410-22-88, 8-986-712-79-79.

**ТАКСИ**

1582 Пассажирское Агентство «Апельсин» г.Казань. Тел. 8-905-375-33-33, 8-906-322-66-66.

**“Маяк” газетасы редакциясенә Аида Хәйртдинованың “Кышкы юл озын иде” китабы сатуга кайтты**

*Китап сөючеләр игътибарына!*



“Маяк” газетасы редакциясенә Башкортстан язучысы Аида Хәйртдинованың яңа гына табадан төшкән “Кышкы юл озын иде” исемле китабы сатуга кайтты.

Авторның әлеге китабына кергән повесте һәм хикәяләрендә заманыбызның төрле кешеләре тасвирлана. Укучыларны туган як, туган җир, яхшылык белән яманлык төшенчәләре турында уйланырга этәрә, геройларның хис-кичерешләре аша безгә, укучыларына, әхлак дәресләре бирә.

«Кышкы юл озын иде» повесте беренче җөмләсеннән үк әсирлеккә ала һәм сюжет буе җибәрми.

Реклама 16+

***Якыннарыгызны видеокотлау белән шатландырыгыз!***

Әти-әниегез, туганыгыз, күршегез яки хезмәттәшегезнең туган көнеме? Әйдәгез, көтелмәгән бүләк ясап, аларга видеокотлау аша иң изге, җылы теләкләребезне җиткерик!

Үз эченә сез тәкъдим иткән фотоларны да алган видеокотлау рәсми сайтыбызда урнаштырылачак, аны социаль челтәрләр аша тарату мөмкинлеге дә бар. Иң мөһиме, якыннарыгызны сез көнендә котлап, аларны сөендерә аласыз!



**Белешмәләр өчен телефон: 9-39-80.**



**Реклама**

1617 **В связи с увеличением объема производства требуются:**

- конструктор,
- мастер участка,
- токарь,
- резчики.
- слесарь по сборке металлоконструкции.

Условии: официальное трудоустройство, белая зарплата.

График работы 5/2, зарплата достойная.

Требования: без вредных привычек, умение знать чертеж.

**Тел. 8-987-183-71-03.**

Реклама

*Елмаеп алыйк әле*

– Хатын миңа малайга исем эзләргә кушты!

– Ә нигә хатының катнашмый?

– Ул атасының исемен эзли!..

***

– Озак яшәвегезнең серен әйтә алмассызмы?

– Җирләргә акчам юк...

***

Бер хатын иренә телефоннан җавап бирә:

– Мин бит сиңа татарча, биш минуттан кайтам, дидем. Ни пычагыма ярты сәгать саен шалтыратып торасың?!

***

Ире кичен хатынына шалтырата:

– Сәлам, кадерлем, син кайда?

– Мин синнән ерак түгел, кафедагы күрше өстәл артында.

***

Бер ир эштә телефоннан сөйләшә.

– Әйе, матурым. Шулаймы? О, котлыйм! Булдыргансың!

Телефонын куя да:

– Егетләр, бетте баш! Минеке права алган!..

**Ишеткәннәрдән**
**Расих Шакирҗанов язып алды**

# Гомергә онытылмаслык сәяхәт

Балачак хатирәсе

Районда пионер отрядлары арасында барган социалистик ярышта Үчәлле сигезьеллык мәктәбенең 7 нче сыйныф отряды 1961-62 уку елы нәтиҗәләре буенча җиңүче булды. Май ае азагында сыйныф җитәкчесе, мәктәпнең пионер дружинасы вожатые Хәлимә апа Мәгъданиева безгә, 6 малай һәм 7 кызга, юлга әзерләнергә кушты: безнең отрядка бүләк итеп экскурсия биргәннәр. Кая диген – Казан-Ульяновск!

Армиядән кайткан абыйларның букчаларына (вещьмешок) пешкән йомыркаларны гәҗит белән төреп тутырдык (ә башка нәрсә бар иде инде ул вакытта авыл өендә җәй көнендә). Пионер галстукларын үтүкләп куйдык.

Колхозның йөк машинасына төялеп, кичен Азнакайның 1 нче мәктәп торагына килеп урнаштык. Иртән безгә Усманов Самат Батталович җитәкчелегендә Азнакай җыелма командасы кушылды. Ул вакытта Азнакай шәһәр булмаса да, бу коллектив үзен иркен, эре тота. Алар гөр килеп автобуска урнаштылар, без дә тыныч кына калган урыннарга утырыштык. Әлмәттә икенче автобуска күчеп, Чистай шәһәренә килеп җиттек.

Без 30 лап 13-15 яшьлек малайкызлар. Группаны алдан физкультура укытучысы Усманов ияртеп бара, колоннаның азагын Хәлимә апа күзәтә. Теплоходка траптан керәбез, ул чайкала, суга егылудан куркыта. Авылда казлар күленнән башка сулык күрмичә үскән балаларга Кама – Идел елгалары кушылган урындагы сусаклагыч – чиксез океан иде.

Экскурсия күп кырлы булып чыкты. Елга теплоходы безне Ульяновск шәһәренә җиткерде. Без көндез экскурсияләрдә. Шау-гөр килеп, шәхси йортлар урамыннан, тротуардан барабыз. Ике катлы агач йорт каршында туктадык. Ленин бабай туып-үскән йорт икән. Экскурсовод Володя Ульяновның мондагы тормыш чорын бәйнә-бәйнә аңлата, без авыз ачып тыңлыйбыз.

Казанда безне Казанка елгасы тирәсендә бер мәктәпнең физзалына ятаклар тезеп урнаштырдылар. Татарстан Республикасы милли музеенда булдык. Ул 1894 елда салынган, бинасының матурлыгы, эчендәге бизәлешләр, анда нинди генә экспонатлар юк!

Бер кичне Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театрына алып бардылар. Ул сугышка хәтле төзелә башлап, 1956 елда гына эшли башлаган. Безне аның мәһабәт зур бинасы, бигрәк тә түшәм уртасына асылынган тоннадан артык люстрасы, тышының, эченең бизәлеше шаккатырды. “Кодача” музыкаль комедиясен карадык, бик тә күңелле булды.

Зур кала белән агач утыргычлы трамвайларда, ачык тәрәзәле троллейбусларда да танышып бардык. Шәһәр эченә урнашкан аэропортның коймасы аркылы самолетларның төшүләрен, очып китүләрен карадык. Бу тирәдәге казанлылар аларның тавышына ничек түзеп яшиләр икән?

Кичләрен мәктәпнең ишек алдында волейбол уйнадык. Беркөнне безнең белән уйнарга шул тирәдә яшәүче малайлар да килделәр. Кеше күп булгач, уен күңеллегә әйләнде. Ләкин бер башкала малае үзенең кем икәнен күрсәтәсе килдеме, тупны пәке белән тишеп шартлатты. Ярый әле тавышка безнең Самат абый чыкты. Ул Казан малайларын ачуланды, кунакларны алай каршыламагыз, дип аңлатты.

Туган якларга бик сагынып кайттык. Әти-әниләр дә балаларын бик сагынганнар. Җитмәсә, ниндидер шомлы хәбәр таратканнар: Кама елгасында бер теплоход авариягә очраган, имеш. Бала чактагы дөнья белән танышу сәяхәтен оештырган укытучыларга, пионер оешмаларына гомер буе рәхмәтле булып яшәдек.

**Ухтияр Илюхин**

Гамәлгә куючы – “ТАТМЕДИА” АҖ

**www.aznakaevo-rt.ru**

Реклама хезмәте телефоны: 8(85592)9–39–80

МАЯК

Азнакай муниципаль районы газетасы

“ТАТМЕДИА” АҖ филиалы директоры - баш мөхәррир

Ф.Ф.Шәйхулов

Редакция адресы: 423330, Азнакай шәһәре, М.Хәсәнов ур., 12
Электрон адрес: azmayak@ mail.ru
Сайт адресы: *www.aznakaevo-rt.ru*
Телефоннар:
9–43–57- кабул итү бүлмәсе,
9–39–80- реклама бүлеге, факс.
Нәшер итүче: “ТАТМЕДИА” АҖ
420097, Казан шәһәре, Академик ур, 2.

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2013 елның 16 маенда ПИ № ТУ16-01015 нче таныклык белән теркәлде
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы “Идел-Пресс” полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2 нче йорт.
Газетаны басарга график буенча 14.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш, фактта - 14.00 сәгатьтә кул куелды.

Тираж - 2867 данә.

"Татмедиа" республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән оештырылды

Редакция фикере һәрвакытта авторлар фикере белән туры килми.
Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк.
Кульъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
Реклама белдерүләренең дөреслеге өчен реклама бирүче җаваплы.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.

Газета чәршәмбе, җомга көннәрендә чыга.
Заказ №7144
Газетага язылу индекслары:
физик затлар өчен – 00050;
оешма-предприятиеләр өчен – 00051.

Сату бәясе ирекле.

16+